**Питрәч үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре**
**Үзәк китапханә**

# «Хисләремә сафлык сарылган...»

**/ Җирле шагыйрәләребез белән очрашу- кичә һәм аларның беренче тапкыр дөнья күргән китаплары белән таныштыру кичәсе /**

**Төзүче:**
**Павлова Н.И.**

**Питрәч, 2018 ел**

# Хисләремә сафлык сарылган...

/ Жирле шагыйрәләребез белән очрашу- кичә һәм аларнын беренче тапкыр дөнья күргән китаплары белән таныштыру кичәсе /

(Музыка астында кунакларны алдан хәзерләгән өстәл артына утырту)
(Матур итеп сәхнә бизәлгән, китап күргәзмәсе, матур гына талгын музыка яңгырый. Ике алып баручы чыга)

**1.а.б**

Келәм чигәм нәфис җепләр белән,

Чигәм аны чагу төсләрдән.

Энәм узган урау юлларыма

Күңелем бизәкләре өстәлгән.

Еллар мине барыбер үзгәртмәде,
Балачакта шыткан хисләрем
Гел беренчел сафлыгында калып,
Балкый алар бөтен төсләрен.

**2.а.б. Исәнмесез хөрмәтле кунакларыбыз, иҗатташ дусларыбыз**! Бүген сезне үзәк китапханәбездә, очрашу – кичәбездә күрүебезгә бик шат.

**1.а б.** Һәр халыкның үзенчә чын милли көе, җыры, җан азыгы, күңел көзгесе бар. Безнең Питрәч төбәгенен дә үз җырчылары, рәсаммнары, шагыйрьләре һәм язучылары бар.

**2 а.б** Табигатьтә - галәмдә һичбер нәрсә бер-берсен кабатламый. Хәтта кар бөртекләре дә охшаш түгел, кеше язмышлары турында сөйлисе дә юк.Тик шунысы уртак: Җир йөзенә без барыбыз да яратырга, бәхетебезне табарга, җиребезне матурларга килгәнбез.

**1 а.б** Бу дөньяда пыскып түгел, ә гөрләп, янып яшәргә,үзеңә бирелгән гомер юлын лаеклы үтәргә, артыңнан якты эз калдырырга тырышырга кирәк. Бүген кичәбез кунаклары – туган якның гүзәллеген,сихри көчен, язмыш сынауларын, горурлану,соклану хисен шигъри юлларына салган шагыйрәләребез –Мария Максимова, Мәдинә Мортазина, Гөлфирә

Һидиятова, Николай Александров, Гүзәл Сафина, Анастасия Долгова. Әйдәгез, кунакларыбызга алкышлап каршы алыйк

**1 аб.** Бәйрәмебезнең төп сәбәпчесе булган хөрмәтле шагыйрәләребез! Сезнең иҗат җимешләрегез район һәм матбугат битләрендә яктыртылып, бездә горурлану хисе тудыра. Әйе, безнең туган җиребездә мондый талант ияләре яшәү безнең өчен бик зур куаныч.

**2 аб.** Беренче китап – һәр шагыйрь өчен зур вакыйга . Ә бүгенге очрашу шагыйрь өчен дә, укучы өчен дә үзенә күрә зур бәйрәм диясе килә, китап – бакча, андагы язучылар- шул бакчаның гөлләре

Кеше кайчан шигырь яза башлый соң?дигән сорауга ...
- Күңелендә яңа фикерләр уянып, кешегә әйтер сүзе, поэтик табышы булганда- дип җавап бирә безнең - Шагыйребез Николай Сергеевич Табигатьне сизгер күзәтүче, аны үзенчә күрә белүче, тылсымлы бизәкләр табып, сүрәтләр ясаучы, Шагыйребез ул “Вперед, “Алга ” газетасының баш мөхәррире Николай Сергеевич Александров, Әйдәгез үзенә сүз биреп үтик әле...

Альбина Кибякова (“Җилләр уйный” шигырен укый)

**1 аб** . Шигърият үз серләрен һәркемгә дә ачмый. Бары ,әйтергә үз сүзе булганнар,тормыш агышына-моңына сизгер күңеллеләр генә шигырь иҗат итәргә сәләтле, минемчә.

Яратылып һәм яратып яшим
Кунак булып килгән дөньяда,
Мең рәхмәтле Ходаем алдында-
Саклаучы фәрештәм янымда- дөньяга килгән һәрбер адәмнең яратып, яратылып яшисе килә. Кешеләр укымышлы, намуслы, эшчән, гади, изге, саф күңелле, кеше күңелен рәнҗетми , җәрәхәтләми торган булсыннар иде. -дип яза безнең шагыйрәбез Мария Ханым Максимова, “ Төшем минем язмышым” дип аталган шигырьләр һәм хикәяләр җыентыгында , Хөрмәтле укучылар бүген без сезгә Мария Григорьевна Максимованың Яңа гына дөнья күргән “Яшьлегем аланы” дип исемләнгән шигъри җынтыгын тәкъдим итәбез безгә сөйләп узсагыз иде? Мария Григорьевна иҗатыгыз белән таныштырып үтсәгез иде? Нинди сәбәпләр этәрде сезне иҗади юлга?

(М. Максимова иҗади юлын сөйли.)

**Музыкаль тәнәфес: (Халимов Ильнур баянда уйный)**

**Мирсаетов Бахтияр “Чәчкәләрем ” шигырен укый**

**2 аб.** Районыбызның гүзәл табигате, сәнгатьле кешеләре, тырыш, уңган халкы элек – электән үк билгеле. Бәлкем нәкъ менә яшәгән мохитегез сезгә илһам ачкычлары биргәндер... Чөнки күңелдә туган хисләр алар беркая да юкка чыга алмый, йөрәкне биләп ала. Шагыйрә Саҗидә Сөләймәнованың бу хакта мондый шигъри юллары бар:

Хәләл-хәрамдырмы якыннардан
Аерып алган сәер хөррият.
Әсир итте сихри ул-хөррият-
Исеме аның – иҗат, шигърият!

Үзенең матур табигате, тоз наратлары, уралып аккан Мишә елгасы, унган- тырыш халкы белэн күплэрне узенэ тартып торган, жырларда жырланган Күн авылында алты балалы гаилэдэ дуртенче бала булып Голфирэ ханым аваз сала. Урманнарда жилэк жыеп, Мишэ суларында коенып, жырга монга гашыйк булып усэ Гөлфирэ. Шагыйрэбезнең « Йорэк жыр сорый» һэм « Яшь талларга вэгъдэ» “Нурлы да син, моңлы да син, гомер жэем”, “Яшьлек хатирәсе” дигэн жыентыклары донья күрэ.
Әйткәнемчә, туган як темасы, яшьлекне сагыну, дуслар, гөлләрем,әниләргә багышланган шигырьләрен укып Гөлфирә ханым Һидиятова Галимуллина иҗаты туган төбәгебездә күпләребез таныш, Әйдәгез әле Гөлфирә ханымның “Соклану ”шигырен тыңлап үтик. Гөлфирә ханым, шигырлэрегезне язганда, сездә нинди хисләр уяна? шигырлэрегезнен Язылу тарихы турында бер-ике сүз әйтеп үтсәгез иде.

(Гөлфирә ханым иҗат юлын сөйли)

Аделина Шарова “Соклану ” шигырен укый

**2 аб**. Иҗат кешесен нечкә күңелле, хисле йөрәкле итеп кабул итәбез. Шигырь язу-һәркем өчен дә бирелгән талант түгел дип уйлыйм мин. Күк йөзендә кабынучы йолдызларның да төрлесе була. Кеше язмышы да йолдызларны хәтерләтә. Берәүләр беленер-беленмәс сүрән яктылык бирсәләр, икенчеләр исә күз камаштырып, балкып яналар. Иҗат күгендә балкып кабынган йолдызыбыз, Иске йорт авылында туып – усеп, хәзерге вакытта Казан каласында гомер итүче Мәдинә Мортазина- Дәминова
Күңелдә ни, телемдә шул,
Сездән минем серем юк,
Күңелдәге хис- тойгыны,
Язып куймый хәлем юк - дип яза Мәдинә ханым “Ямьле язда килде көзләрем” дип исемлэнгән шигырьләр җыентыгында, Мэдинэ ханым сүзне

сезгэ бирэбез, сезне ижат юлына  нинди тойгы-кичерешләр этэрде, , ничәнче елдан бирле ижат итэсез?

Заман җилләренә бирешмичә,
Яши әле минем авылым.
Алла боерса, гомер биргән кадәр
Туган авылымда калырмын

**1 аб.** Кеше күңелендәге тойгыларның агышын елга агышына ошатып була микән? Мөгаен, буладыр. Күңел агымының да ярсып шаулаган дәһшәтле бусагалары, җәелеп аккан тугайлары, шомлы чоңгыллары һәм чит күзләргә күренмичә генә, сабыр һәм тын гына гомерлек уйга талган яр куеннары була. Шигъри хис тә күңелдә табигатьнең бер халәте буларак туа. Гомер сукмагында аллы-гөлле чәчәкләр генә балкып утырмый. Әлеге сукмакта кешене зур югалтулар, көенечләр дә сагалап тора.Күңелгә дөньяның яңгыр җиле килеп кагылган икән, син гамьсез генә яши алмыйсың. Яшәешнең һәр мизгеле каныңда олы гамь тойгысы булып сулкылдый.Ул тойгы сүзләргә күчә, шигырьгә әверелә. Гаҗәеп шагыйрә  Гүзәл Сафина бездә бүген кунакта, Шагыйрэнен  бик  куп  ижат  жимешлэре,  уз  гаилэсенэ, туганнарына, дусларына  багышланган  дисэм дэ  ялгышмам  тосле.

- Сезнең тормыш юлыгыз да  шатлыклы-кайгылы мизгелләр дә булгандыр  . Авыр вакытларыгызда каләм сезгә ярдәмгә килдеме? Мөмкин булса безгә берәр шигырегезне укып китсэгез иде?

(Г.Сафина сөйли)

**2 аб.** Кешегэ табигать биргэн талантны - кунел агымнарының барлык серлэренэ шаhит тирэн күккэ ошатасым килэ. Элбэттэ,hэркемнен күңел агышы үзенчэ, күге үзенчэ. Шигырь китапларын  укыганда  hәрбер шигъри юлларны күңел аша  үткәреп тоясы ,  үзеңнеке итеп кичерэсе килэ. Эгәр дэ без  шагыйрьнен ни эйтергэ  телэгэнен,  анын кунел  талпынышларын беренче  укуда  ук  тоябыз, анлыйбыз,  уз  итәбез икэн,  димәк шигырь бар, шигърият  бар. Хөрмәтле укучыларыбыз сезне тагын бер  мөләем шагыйрә Анастасия Макаровна Долгова  белән таныштырып үтәсебез килә., шагйрәбез Анастасия Макаровнага үзенә сүз бирип утик әле

(А.Макаровна сөйли)

1 аб . Шагыйрьэлэребезнен ижатында  ата- ана  хислэре, дуслык  тойгылары. Туган  жиргэ мэхэббэт, дөнья  иминлеге,   телебезгэ,  хезмэткэ, олкэннэргэ, гомумэн  кешелэргэ  ихтирам…hэм  хэрберсенэ  тирэн  мон  сенгэн. Шагыйрь уз шигырен язганда тойган лэззэтен  укучыларга   яки тынлаучыларга  житкерэ  алса гына  бэхетле.

**2 а.б** .Яшик шулай бер-беребезне зурлап,
Туган җирне зурлыйк иң элек.
Гомер мизгел, гомер үтә-китә
Яхшылыклар гына мәңгелек.

**1.а.б.** Рәхмәт сезгә, мәңге шулай
Тыйнак гүзәл булып калыгыз
Югалтмыйча күңел энҗеләрен
Киләчәккә алып барыгыз.

Ә хәзер сүз китапханә мөдире Зимфира Расиловна Ахметшинага бирелә.(Килгән кунакларга истәлекле бүләк тапшыру)

Язучының каләме кәгазь өстеннән йөгерә. Чөнки аның кешеләргә ул гына әйтә алган кадерле сүзләре бар. Коры фикерләр белән генә түгел, шулар янына хис, тойгы да өстәп эшли ул моны. Менә ни өчен аның сүзе бик күпкә үтемлерәк була. Язучы каләме бары тик игелекле фикерләр, тойгылар гына белдерсә, бүгенгебез, киләчәгебез имин, матур булыр.

Хөрмәтле кунакларыбыз бүгенге очрашу- кичә ахырына якынлашты! Шигъри аланнарыгызда яңгыр җилләре тынмасын; ул җилләр җырын, җилләр моңын сезнең каләм аша халык укысын- тыңласын! дигән теләктә калабыз. Яңадан –яңа иҗади җыентыкларыгызны көтеп калабыз, иҗади уңышлар сезгә,

**Сораулар**

Анастасия Макаровна  Шигьри жанлы, хисле булып үсүегезгә нэрсэ этэргеч булды.? Белгэнебезчэ шигырь, аерым бер шэхеснен хис вэ фикер жимеше, таянычы, юанычы, юлдашы дилэр? Сез бу хакта ни эйтэ аласыз?

Мария Григоьевна яраткан шагыйрэгез кем? Хэм ул башкалардан кайсы ягы белэн аерылып тора?

Шигырь энжелэре ничек барлыкка килэ ? Ин беренче язган шигырегез ничек ди атала?

Голфирэ апа сезне бик матур жырлый дилэр. Безгэ берэр яраткан жырыгызны булэк итмэссез микэн?

Гүзәл апа  Сезне нинди тема күбрэк җәлеп итэ?

Мария апа язган шигырьлэрегезне беренче булып кемгэ укытасыз?

Николай Сергеевич Шигьри осталык серлэре нидэ?

Мәдинә ханым,- иртэн уянгач, кунелегезгэ нинди уйлар килэ? гомумэн иртэгез нидэн башлана?

Николай Сергеевич - Хэр ижат кешенен остазлары була, кемгэдер ул «балалык» чорыннан чыгарга булыша. Сез кемнэр белэн ижади бэйлэнештэ уз сукмагыгызны таптыгыз?

Гөлфирә Галимуллина - Озак яки ботенлэй язмыйча торган вакытлар булгалыймы? Язу искиткеч авыр, э язмый тору тагын да авыррак ди поляк язучысы Тадеуш Бреза. Бу сузлэргэ ничек карыйсыз?

Анастасия Макаровна - Хыялсыз кеше- канатсыз кош» дилэр.Тормышка ашарга момкин булган ин зур хыялыгыз нинди?

Гүзәл апа - Бу очрашу сездэ нинди уй-тойгылар уятты?

Мария Григорьевна- Язучылдар хисчэн булла дилэр. Кунелегез нечкэреп, бу катлаулы тормышка упкэлэгэн чакларыгыз бармы?

Мәдинә апа - Тормышнын сикэлтэле юлларын узганда ярдэм итэрлек, таянырлык чын дусларыгыз бармы?

**Кулланылган әдәбият**


1. Голсирэ Солтанова Китмэ, сою//Мэдэни Жомга.1998ел.16б

2. 10. Голфирэ Хидиятова “Йорэк жыр сорый”Питрэч 2009 ел.2б.

3. 11.Голфирэ Хидиятова “Яшь талларга вэгъдэ”Питрэч 2009 ел.2б.
4. Клара Булатова “Шушы яктан,шушы туфрактан без”Казан, 2000 ел. 5-22б.

5. Максимова М. “Яшьлегем аланы” Питрәч , 2017ел.4-68 б

6. Золфия Гыйниятова “Сагынам”Питрэч,2009ел.2б
7.Резедэ Вэлиева “Китмэ,сөю”. Казан.1998. 5 б.

8.Флера Тархонава “Синен кайнар сулышын”Казан.1997. 6-7б.

9. Шэрифуллина Эльмира "Янгыр жиле”Казан.1984.5-6 б.

10. Шэрифуллина Эльмира “Союемнэн мин бер чибэр идем” Казан,2005 ел,5 -8 б.

11. Шагыйрьжан Лена. Шигырьлэр,поэма.Казан 1996 ел,3-10 б

12.“Питрэч таннары”эдэби сэхифэсе.//Алга.21 октябрь,3б

13.Гузэл Сафина”Ак хыяллар иле”Питрэч,2008 ел.2б.


Якташларыбыз иҗаты






ЦЕНТРАЛЬНЫЕ
ГАЗЕТЫ



















































